**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ**
**ТУКАЙ МУНИЦПАЛЬ РАЙОНЫ**
**БИКЛӘН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ**

**КАРАР**

“10” ноябрь 2023 ел Биклән авылы №4

**“Татарстан Республикасы Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең Бакчасарай авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм алардан файдалану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында”**

“Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында” 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56 статьялары, “Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында” 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы, Тукай муниципаль районы “Биклән авыл җирлеге” муниципаль берәмлеге Уставының 13.1 ст. нигезендә

**КАРАР БИРӘМ:**

1. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлегенең Бакчасарай авылында 2023 елның 21 ноябрендә 15.00 сәгатькә үзара салым кертү мәсьәләсе буенча гражданнар җыены билгеләргә.
2. Гражданнар җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:

“Биклән авыл җирлегенең Бакчасарай авылы территориясендә 2024 елда балигъ булган, Биклән авыл җирлегенең Бакчасарай авылы территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр кешегә 3000 (Өч мең) сум күләмендә бер тапкыр түләү кертергә һәм I һәм II группа инвалидларга һәм Бөек Ватан сугышы ветераннарына, ялгыз карт гражданнарга һәм көндезге формада укучы студентларга, күп балалы гаиләләргә бер тапкыр түләүне киметергә һәм аны әлеге категория гражданнар өчен 1500 (Бер мең биш йөз) сум күләмендә билгеләргә, аларның суммасы түбәндәге мәсьәләләрне:

**- Бакчасарай авылының сууткәргечен реконструкцияләү.**

**“ӘЙЕ” “ЮК”.**

3. Татарстан Республикасы, Тукай районы, Бакчасарай авылы, Мәрдеев урамы, 38а йорты адресы буенча гражданнар җыенын үткәрергә.
4. Тукай муниципаль районы Биклән авыл җирлеге башкарма комитетын Гражданнар җыенын оештыручы итеп билгеләргә.
5. Әлеге карарны авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.
6. Әлеге карарны Тукай муниципаль районының рәсми сайтында “авыл җирлекләре” бүлегендә һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында урнаштырырга.
7. Әлеге карар халыкка җиткерелгән көннән үз көченә керә.

Биклән авыл җирлеге Башлыгы М.Ш.Сәхбеев

Совет БИКЛЯНСКОГО сельского поселения